Республика Татарстан
Глава Тихоновского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423655, Менделеевский район, с. Тихоново,
ул. Шишкина, д.3а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге Башлыгы
423655, Менделеевск районы, Тихоново авылы,
Шишкин урамы, 3а

тел./факс 8/85549/3-43-62, E-mail: Tihon.Men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 ноябрь 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Тихоново авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенын этаплап үткәрүне 2025 елның 21 ноябренә билгеләргә.

1.1. Тихоново авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Коммунистлар урамы, 1-43 йортлар - 15сәг.30 мин

Икенче этап: Шишкин урамы, 1-56 йортлар, Яшьләр урамы,3,9 йортлар, Үзәк урам 5 йорт – 16сәг.30 мин.

Өченче этап: Тойма урамы, 1-44 йортлар, Урман урамы, 1-24 йортлар- 17 сәг.30 мин.

1.1. Җыеннарны барлык этапларын уздыру урыны итеп Менделеевск районы, Тихоново авылы, Коммунистлар урамы, 27В йорт адресы буенча урнашкан Тихоново авыл мәдәният йортын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:
"2026 елда Сез үзара салым акчаларын I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк затлардан тыш, Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә күпбалалы гаиләләрдән 50%ка киметеп 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?":

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тихоново авылында асфальт түшәмәле юлларны төзекләндерү һәм чокырларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту);

2) һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы ядкарен ремонтлау һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (печән чабу, Коммунистлар урамындагы 6, 8, 10 нчы күпфатирлы йортлар янында киртәләр урнаштыру);

4) урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктырту баганаларын урнаштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru "Тихоново авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гәрәева